| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.10.2024 п г т Алексеевское № 440

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү-күнекмә чараларын уздыру чыгымнары нормаларын раслау турында**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү-күнекмә (күнекмә) чараларын уздыру чыгымнары нормаларын тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 21.09.2019 ел, № 868 «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.03.2015 ел, № 160 «Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт Министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм күнекмәләр чараларын уздыруга чыгымнар нормаларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карарына таянып

**карар бирәм:**

1.Расларга:

- физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү-күнекмә чараларын уздырганда спортчыларны, тренер-укытучыларны, машина йөртүчеләрне, белгечләрне һәм хезмәт күрсәтүче персоналны туклану яисә тәүлеклеклек белән тәэмин итү чыгымнары нормалары (1 нче кушымта);
- физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү-күнекмә (күнекмә) чараларында спортчыларны, тренерларны, машина йөртүчеләрне һәм башка катнашучыларны яшәү белән тәэмин итү чыгымнары нормалары (2 нче кушымта);
- спорт чараларына хезмәт күрсәткән өчен спорт судьяларына түләү чыгымнары нормалары (3 нче кушымта);
- спорт чараларында катнашучылар өчен фармакология, тернәкләндерү чаралары, витамин һәм аксым-глюкоза препаратлары, гомуми дәвалау билгеләнешендәге медикаментлар һәм бәйләү материаллары белән тәэмин итү чыгымнары нормалары (4 нче кушымта);

- физкультура һәм спорт массакүләм чараларына хезмәт күрсәткән өчен административ-хуҗалык һәм хезмәт күрсәтүче персоналга түләү чыгымнары нормалары (5 нче кушымта).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгеленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 28.09.2022 ел, №418 «Алексеевск муниципаль районының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү-күнекмә чараларын уздыруга чыгымнар нормаларын раслау турында», 01.10.2024 №412 «Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 28.09.2022 ел, №418 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү-күнекмә чараларын уздыруга чыгымнар нормаларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» Карарларын үз көчләреннән югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_18.10.2024 ел, № _440_
карарына 1 нче кушымта

**Физкультура-савыктыру, спорт һәм ойрәтү-күнекмә чараларын уздырганда спортчыларны, тренер-укытучыларны, машина йөртүчеләрне, белгечләрне һәм хезмәт күрсәтүче персоналны туклану яисә тәүлеклеклек белән тәэмин итү чыгымнары нормалары**

| № т/б | Спорт чаралары исеме | Көнгә бер кешегә чыгымнар нормасы, сум |
|---|---|---|
| 1. | Массакүләм физкультура-спорт ярышлары һәм чаралары | 365 кә кадәр |
| 2. | Татарстан Республикасы чемпионатлары, беренчелекләре, кубоклары һәм аларга күнекмә чаралары(спартакиадалар, универсиадалар) | 425 кә кадәр |
| 3. | Бөтенроссия ярышлары һәм аларга тренировка күнекмә чаралары | 730 га кадәр |
| 4. | Олимпия уеннарына карамаган һәм паралимпиягә карамаган спорт төрләре буенча халыкара ярышлар һәм аларга күнекмә чаралары | 785 кә кадәр |
| 5. | Олимпия һәм паралимпия спорт төрләре буенча халыкара ярышлар һәм аларга күнекмә чаралары | 850 гә кадәр |
| 6. | Алексеевск муниципаль районы территориясендә | 200 гә кадәр |
| 7. | Алексеевск муниципаль районыннан читтә | 425 кә кадәр |

Искәрмә:

1. Авырлыгы 90 килограммнан артык һәм / яки буе 190 см дан югары булган спортчыларга аерым очракларда әлеге кушымтада билгеләнгән нормалар каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә 50 процентка кадәр күтәрелергә мөмкин.

2. Акчасыз исәп хисап буенча спорт чараларын уздыру урыннарында туклану яисә тәүлеклек белән тәэмин итү мөмкинлекләре булмаганда, спорт чараларында катнашучыларга әлеге кушымтада китерелгән чыгымнар нормалары чикләрендә акчалата акча бирү рөхсәт ителә.

3. Татарстан Республикасы территориясендә уздырыла торган Бөтенроссия ярышларында катнашучы спортчылар республика ярышлары чыгымнары нормалары чикләрендә туклану яисә тәүлеклеклек белән тәэмин ителәләр.

4. Спорт чараларын үткәргәндә спорт судьяларының барлык категорияләре дә тәүлеклеклек белән тәэмин ителми.

5. Чараларны үткәрүче оешмалар бюджеттан тыш, иганәчелек акчалары, шулай ук заявка кертемнәре исәбеннән барлык категория судьяларга, спортчыларга, тренерларга, машина йөртүчеләргә һәм белгечләргә туклану өчен компенсация түләүләре яисә тәүлеклек түләүләр башкарырга хокуклы.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_18.10.2024 ел, № _440_
карарына 2 нче кушымта

**Физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү-күнекмә (күнекмә) чараларында спортчыларны, тренерларны, машина йөртүчеләрне һәм башка катнашучыларны яшәү белән тәэмин итү чыгымнары нормалары**

| № т/б | Яшәү өчен торак пунктларның категорияләре исеме | Бер кешенең-көннең бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Мәскәү, Санкт-Петербург, Сочи шәһәрләре | 1120 гә кадәр |
| 2. | Россия Федерациясе субъектларының административ үзәкләре; Ерак Төньяк территорияләренә кертелгән шәһәрләр, торак пунктлар | 1120 гә кадәр |
| 3. | Россия Федерациясе территориясендәге башка шәһәрләр һәм торак пунктлар | 850 гә кадәр |

Искәрмә:

1.Спортчыларны, тренер-укытучыларны,башка катнашучыларны һәм физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәнү-тренировка (тренировка) чараларында акчасыз исәп-хисап буенча яшәү белән тәэмин итү мөмкинлеге булмаганда, әлеге кушымтада китерелгән чыгымнар нормалары чикләрендә акчалата акча бирү рөхсәт ителә.

2. Ярышларда яшәү мөмкинлеге булмаган очракта, чыгым нормаларында күрсәтелгән сумма, каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә, тәүлегенә 1300 сумга кадәр күтәрелергә мөмкин.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
18.10.2024 ел, № 440
карарына 3 нче кушымта

**Спорт чараларына хезмәт күрсәткән
өчен спорт судьяларына түләү
чыгымнары нормалары**

| № т/б | Судья вазыйфаларының аталышы | Судьялар категорияләрен исәпкә алып түләүләр күләме, сумнар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ХАК,БК | 1К | 2К | 3К/Я/С | категориясез |
| 1. | Баш судья | 745 | 630 | - | - | - |
| 2. | Баш судья -секретарь | 745 | 630 | - | - | - |
| 3. | Баш судьяның, баш секретарьнең урынбасары | 685 | 570 | 455 | - | - |
| 4. | Судьялар | 640 | 510 | 435 | 400 | 340 |
| Командалы уен спорт төрләре | | | | | | |
| 5. | Уенның баш судьясы | 435 | 400 | - | - | - |
| 6. | Уенның баш судьясы ярдәмчесе | 365 | 340 | - | - | - |
| 7. | Инспектор (техник делегат, комиссар) | 435 | - | - | - | - |
| 8. | Судьялар (бригада составында) | 330 | 310 | 285 | 260 | 230 |

Шартлы билгеләр:
ХАК – халыкара категорияле спорт судьясы;
БК – бөтенроссия категорияле спорт судьясы;
1К – беренче категорияле спорт судьясы;
2К – икенче категорияле спорт судьясы;
3К – өченче категорияле спорт судьясы;
Я/С –яшь спорт судьясы.

Искәрмә:

1.Түләүләр күләме ярышларның бер көненә хезмәт күрсәтү өчен каралган, командалы уен спорт төрләреннән тыш, анда бер уенга хезмәт күрсәтү өчен түләүләр башкарыла (футбол, алкалы хоккей, баскетбол, волейбол, су полосы, гандбол, туплы хоккей, чирәмдәге хоккей, бейсбол, регби һ. б.).

2.Ярышларның әзерлек һәм йомгаклау этабында баш судьяга, баш судья-секретарьга, баш судья урынбасарына һәм баш судья урынбасары–секретарьга яшәү, эш өчен түләү өстәмә рәвештә 2 көнгә арта.

3.Судьялар коллегияләренең (бригадаларының) сан составы спорт төрләре буенча ярышлар уздыру турында расланган кагыйдәләр нигезендә билгеләнә.

4.Халыкара, бөтенроссия ярышлары, Татарстан Республикасы чемпионатлары һәм кубоклары уеннарын оештыруны һәм уздыруны тикшереп тору өчен уеннарның баш судьялары өчен каралган күләмдә түләү белән инспекторлар яисә техник делегатлар билгеләнергә мөмкин.

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
18.10.2024 ел, № 440
карарына 4 нче кушымта

**Спорт чараларында**
**катнашучылар өчен фармакология, тернәкләндерү чаралары, витамин һәм аксым-глюкоза препаратлары, гомуми дәвалау билгеләнешендәге медикаментлар һәм бәйләү материаллары белән тәэмин итү чыгымнары нормалары**

| Спорт чаралары исеме | Бер кешегә көнгә чыгымнар нормасы, сумнар | |
|---|---|---|
| | Россия шәһәрләрендә һәм чит илләрдә | Татарстан Республикасында |
| 1.Бөтенроссия һәм халыкара ярышлар: Россия Федерациясе җыелма командасының төп составының (әгъзаларының) җәйге һәм кышкы олимпия спорт төрләре буенча; олимпия уеннарына карамаган спорт төрләре, Россия Федерациясе җыелма командасының резерв составындагы олимпия спорт төрләре һәм паралимпия һәм сурдлимпия уеннары программасына керә торган спорт төрләре буенча | 150-120 гә кадәр | 120 гә 90 га кадәр |
| 2.Тренировка чаралары: Россия Федерациясе җыелма командасының төп составының (әгъзаларының) җәйге һәм кышкы олимпия спорт төрләре буенча; Россия Федерациясе җыелма командасының резерв составындагы җәйге һәм кышкы олимпия спорт төрләре буенча һәм паралимпия һәм сурдлимпия уеннары программасына керүче олимпия уеннары булмаган спорт төрләре һәм паралимпия һәм Сурдлимпия уеннары программасына керми торган спорт төрләре буенча | 500 гә 400 гә кадәр<br><br>300 гә кадәр | 380 гә 300 гә кадәр<br><br>200 гә кадәр |

Искәрмә:

1. Россия Федерациясе спорт җыелма командасының төп составын

(әгъзаларын) рәсми халыкара ярышларга әзерләгәндә медикаментлар белән тәэмин итү «Спорт әзерлеге үзәге» ДАУ боерыгы буенча, спорт табиблары яисә белгечләре белән килештереп, индивидуаль план-фармакологик тәэмин итү графигы нигезендә гамәлгә ашырыла.

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_18.10.2024 ел, № _440_
карарына 5 нче кушымта

**Физкультура һәм спорт
массакүләм чараларына хезмәт күрсәткән өчен
административ-хуҗалык һәм хезмәт күрсәтүче персоналга түләү
чыгымнары нормалары**

| № т/б | Вазыйфалар аталышы | Көнгә түләү күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | Җыен башлыгы (администратор) | 217 |
| 2 | Комендант | 193 |
| 3 | Дистанция һәм трассалар башлыгы | 217 |
| 4 | Дистанция һәм трассалар башлыгы урынбасары | 205 |
| 5 | Җәйге спорт төрләре буенча контролер | 193 |
| 6 | Кышкы спорт төрләре буенча контроллер | 205 |
| 7 | Спорт судноларына хезмәт күрсәтү буенча эшче | 189 |
| 8 | Техник-моторист | 217 |
| 9 | Техник, моторист-коткаручы | 217 |
| 10 | Ратрак (кар машинасы)йөртүчесе | 193 |
| 11 | Водолаз | 217 |
| 12 | Телефончы | 193 |
| 13 | Оператор | 217 |
| 14 | Спорт чараларына хезмәт күрсәтү буенча эшче | 189 |
| 15 | Ярдәмче эшче | 188 |
| 16 | Рәссам | 256 |
| 17 | Видеотехникага хезмәт күрсәтү буенча инженер | 275 |
| 18 | Машинистка | 189 |
| 19 | Аккомпаниатор | 240 |
| 20 | Ветеринария табибы | 275 |
| 21 | Ат караучы | 187 |
| 22 | Механик | 217 |
| 23 | Табиб | 312 |
| 24 | Шәфкать туташы | 241 |
| 25 | Күзәтүче, махсус хәбәрче, матбугат сәркатибе | 275 |

Искәрмә: гамәлдәге хезмәт законнары нигезендә ял һәм бәйрәм көннәрендә түләүләр күләме икеләтә арта.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**